**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

№249-п 01.03.2017

"ЭКОлидер" республика конкурсы уздыру турында нигезләмә раслау хакында

Татарстан Республикасы территориясендә табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итүче предприятиеләрне һәм оешмаларны, шәхси эшкуарларны, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарын, белем бирү оешмаларын, иҗтимагый берләшмәләрне, гражданнарны, журналистларны бүләкләү һәм стимуллаштыру максатында боерык бирәм:

1. Ел саен "ЭКОлидер" республика конкурсы уздырырга.
2. "ЭКОлидер" республика конкурсы уздыру турында нигезләмә расларга.
3. Экологик мәгариф һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлегенә, координацияләү һәм планлаштыру бүлегенә, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү секторына, Министрлыкның территориаль идарәләренә гаризалар кабул итүне оештырырга, "ЭКОлидер" республика конкурсында (алга таба – Конкурс) җиңүчеләрне бүләкләү буенча тантаналы чарага әзерлек тәэмин итәргә.
4. Әйләнә-тирә мохитне саклау икътисады бүлегенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 28 декабрендәге 1083 номерлы карары белән расланган "2014-2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану" дәүләт программасын раслау турында" дәүләт программасы кысаларында, Конкурс оештыру һәм уздыру өчен кирәкле финанс чаралары бүлеп бирүне күздә тотарга.
5. Экологик мәгариф һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы Д.Ф. Вәлиуллинга әлеге боерыкны "Татарстан Республикасы Рәсми порталы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

7. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының "01" 03. 2017
№ 249-п

"ЭКОлидер"
республика конкурсы уздыру турында
нигезләмә

# I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге Нигезләмә "ЭКОлидер" республика конкурсы (алга таба – Конкурс) оештыруның һәм уздыруның максатын, бурычларын, тәртибен билгели.

2. Конкурс уздыруның максаты булып Татарстан Республикасы территориясендә табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек мәсәләләрен нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итүче предприятиеләрне һәм оешмаларны, шәхси эшкуарларны, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарын, белем бирү оешмаларын, иҗтимагый берләшмәләрне, гражданнарны, журналистларны бүләкләү һәм стимуллаштыру тора.

3. Конкурс ел саен номинацияләр буенча конкурс төркемнәре өчен уздырыла. Һәр номинациядә I, II, III урыннар бирү күздә тотыла.

4. Конкурста катнашуга гаризалар Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек башкаручы һәм табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек тәэмин итү мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итүче предприятиеләрдән һәм оешмалардан, шәхси эшкуарлардан, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, белем бирү оешмаларыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, гражданнардан, журналистлардан, басма матбугат чараларыннан, телерадиокомпанияләрдән һәм интернет басмаларыннан кабул ителә.

5. Конкурсны оештыручы булып Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

6. Конкурсны уздыру чорлары, шартлары һәм йомгаклары турында мәгълүмат "Татарстан Республикасы Рәсми порталы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

# II. Конкурсның бурычлары

7. Конкурсның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт экология сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыру;

Җир Хартиясенең төп принципларын популярлаштыру;

Татарстан Республикасында экология хәрәкәтен үстерү;

табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек тәэмин итү мәсьәләләрен хәл иткәндә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән предприятиеләрне һәм оешмаларны, шәхси эшкуарларны, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарын, белем бирү оешмаларын, иҗтимагый берләшмәләрне, гражданнарны, журналистларны ачыклау;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметә торган табигать саклау һәм ресурсларны сак куллану технологияләрен эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән предприятиеләрне һәм оешмаларны, шәхси эшкуарларны, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарын ачыклау;

экологик белем бирү системасын үстерү һәм экологик мәдәният формалаштыру;

экология өлкәсендә үсеп килүче буын эшчәнлеген үстерү;

үсеп килүче буынның туган төбәк табигатен өйрәнүгә һәм аның экологик торышын бәяләүгә юнәлдерелгән тикшеренү эшчәнлеген камилләштерү;

әйләнә-тирә мохит турында белемнәрне пропагандалау һәм аңа карата халыкта сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү;

әйләнә-тирә мохитне яклау проблемаларына карата гражданнарда актив позиция формалаштыру.

## III. Конкурс төркемнәре һәм номинацияләре

| Конкурс төркеме | Номинацияләр |
|---|---|
| Предприятиеләр һәм оешмалар, шәхси эшкуарлар | - нефть һәм газ сәнәгате;<br>- энергетика;<br>- төзелеш сәнәгате;<br>- торак-коммуналь комплекс;<br>- авыл хуҗалыгы һәм урман сәнәгате |
| Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары | - муниципаль район территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге казаныш өчен;<br>- шәһәр территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге казаныш өчен;<br>- авыл җирлеге территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге казаныш өчен |
| Белем бирү оешмалары | - мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында экологик белем бирү;<br>- гомуми белем бирү оешмаларында экологик белем бирү;<br>- югары белем бирүче оешмаларда һәм өстәмә белем бирү оешмаларында экологик белем бирү |
| Иҗтимагый берләшмәләр һәм гражданнар | - иҗтимагый берләшмәләр;<br>- гражданнар;<br>- халык контроле |

| | |
|---|---|
| Массакүләм мәгълүмат чаралары | - иң яхшы телесюжет;<br>- иң яхшы радиосюжет;<br>- иң яхшы электрон ММЧ материалы;<br>- басма матбугат чараларында иң яхшы мәкалә |

## IV. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

8. Конкурста катнашу өчен гариза тапшыручылар мәгълүмат картасын, өстәмә барлык материалларны (алга таба – материаллар) быелның 1 сентябреннән 15 ноябренә кадәр тапшыра.

9. Конкурска түбәндәге материаллар тапшырыла:

әлеге Нигезләмәнең 1-5 нче кушымталарындагы форма буенча тутырылган катнашучының мәгълүмат картасы;

экология программалары (булган очракта);

фотоматериаллар;

рәхмәтләр һәм дипломнар;

Татарстан Республикасы территориясендә табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендә уздырылучы эшләрне тасвирлау;

басма материаллар, түбәндәгеләрне күрсәтеп: мәкаләнең, басма органның аталышы, чыгарылу датасы, автор(лар) һәм басма орган турында белешмәләр;

видео- һәм аудио файллар, түбәндәгеләрне күрсәтеп: материалның, тапшыруның аталышы, эфирга чыгу датасы, автор(лар) һәм теле- һәм радиоканал турында белешмәләр;

фотоэшләр, түбәндәгеләрне күрсәтеп: атамасы, зарурлык булганда тасвирлама теркәп.

10. Материалларны бәяләүдә төп критерияләр булып түбәндәгеләр тора:

комплектланган булу һәм табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендә бурычларны һәм проблемаларны хәл итүдә гамәлдә тормышка ашыра алырлык алымнар;

табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендә бурычларны һәм проблемаларны хәл итүдә инновацияле алым;

оригиналь идеяләр;

катнашучы тарафыннан кулланыла торган чишелешләрне гамәлгә кертү нәтиҗәләрен тасвирлауның анык булуы;

иҗтимагый инициатива һәм социаль файда;

гражданнарның экологик мәдәниятен һәм экологик мәгърифәтлелеген арттыру өлкәсендәге материалларның актуальлеге;

медия ягыннан кызыклы булуы, күрсәтелү яңалыгы һәм мәгълүмати яктыртуның оператив башкарылуы;

нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләрнең куелган бурычларга җавап бирүе, проектларны һәм программаларны тормышка ашыруның санлы һәм сыйфатлы күрсәткечләре).

11. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында каралган материаллар Министрлыкка түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75, кулдан, почта аша яисә электрон почта аша: "ЭКОлидер" конкурсы" тамгасы белән, белешмәләр өчен телефон: 8(843)267-68-11 (экологик мәгариф һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлеге).

12. Конкурста катнашу өчен тапшырылган материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

13. Материаллар кабул ителгәч һәм аларны эшкәртү (тулы булу-булмавын тикшерү, тәгаенләштерүләр һ.б.) тәмамлангач җиде календарь көне эчендә кабул ителгән материаллар карау өчен Конкурс комиссиясенә тапшырыла.

14. Материалларны бәяләү буенча әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында билгеләнгән критерияләр нигезендә Конкурс комиссиясе тапшырылган эшләрне бәяли.

15. Конкурс йомгаклары бу ел азагына кадәр уздырыла.

## V. Конкурс комиссиясе

16. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү өчен Конкурс комиссиясе төзелә, аның составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның шәхси составы үзгәртелгәндә, Министрлык боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

17. Конкурс комиссиясенең эше андагы әгъзаларның кимендә яртысы булганда утырышлар формасында гамәлгә ашырыла.

18. Конкурс комиссиясенә рәис җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, Конкурс комиссиясе рәисе вазыйфалары Конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына йөкләнә.

19. Конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының, Конкурс комиссиясе рәисенең яисә аны алмаштыручы затның тавышларыннан гади күпчелеге белән кабул ителә.

20. Тавышлар тигез булган очракта, Конкурс комиссиясе рәисенең яисә аны алмаштыручы затның тавышы хәл иткеч була.

21. Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, рәис яисә аны алмаштыручы зат һәм Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана.

22. Конкурс комиссиясе сәркатибе Конкурс комиссиясе әгъзалары составына керми һәм аның утырышларында тавыш бирү хокукыннан башка катнаша.

## VI. Конкурс нәтиҗәләре

23. "Предприятиеләр һәм оешмалар, шәхси эшкуарлар", "Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары", "Белем бирү оешмалары" конкурс төркемнәрендә җиңүчеләр диплом һәм кубок белән бүләкләнә.

24. Конкурс комиссиясе карары белән "Предприятиеләр һәм оешмалар, шәхси эшкуарлар" конкурс төркемендә Конкурста катнашучыга өстәмә рәвештә "Абсолют җиңүче" исеме, диплом һәм кубок бирелә.

25. "Иҗтимагый берләшмәләр һәм гражданнар" конкурс төркемендә җиңүчеләр түбәндәге рәвештә бүләкләнә:

| Урыны | Номинацияләр | | |
|---|---|---|---|
| | "Иҗтимагый берләшмәләр" | "Гражданнар" | "Халык контроле" |
| 1 | 40,0 мең сум | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |
| 2 | 30,0 мең сум | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум |
| 3 | 20,0 мең сум | 5,0 мең сум | 5,0 мең сум |

26. "Басма матбугат чараларында иң яхшы мәкалә" номинациясендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге рәвештә бүләкләнә:

| Урыны | 1 төркем – республика ММЧ | | 2 төркем – шәһәрләр һәм районнар ММЧ | |
|---|---|---|---|---|
| | татар телендә | рус телендә | татар телендә | рус телендә |
| 1 | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум |
| 2 | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |
| 3 | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум |

27. "Иң яхшы телесюжет" номинациясендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге рәвештә бүләкләнә:

| Урыны | 1 төркем – республика ММЧ | 2 төркем – шәһәрләр һәм районнар ММЧ |
|---|---|---|
| 1 | 30,0 мең сум | 30,0 мең сум |
| 2 | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум |
| 3 | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |

28. "Иң яхшы радиосюжет" номинациясендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге рәвештә бүләкләнә:

| Урыны | 1 төркем – республика ММЧ | 2 төркем – шәһәрләр һәм районнар ММЧ |
|---|---|---|
| 1 | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум |
| 2 | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |
| 3 | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум |

29. "Иң яхшы электрон ММЧ материалы" номинациясендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге рәвештә бүләкләнә:

| Урыны | 1 төркем – республика ММЧ | 2 төркем – шәһәрләр һәм районнар ММЧ |
|---|---|---|
| 1 | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум |
| 2 | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум |

"ЭКОлидер" республика конкурсы уздыру турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

**"Предприятиеләр һәм оешмалар"**
конкурс төркемендә "ЭКОлидер" республика конкурсында катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация:
______________________________________________
2. Предприятиенең/оешманың тулы атамасы:
______________________________________________
3. Адресы: ТР муниципаль районы: ____________________ торак пункт: _____________ урам: __________________________ йорт: _________________________
4. Оешма җитәкчесенең ФИА:
______________________________________________
5. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның ФИА:
______________________________________________
Вазыйфасы:
______________________________________________
Эш телефоны, коды белән:
______________________________________________
Кесә телефоны:_______________________________________________
E-mail:______________________________________________________
6. Эшчәнлек күрсәткечләре:

| № | Күрсәткеч атамасы, үлчәү берәмлеге | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Җитештерү күләмнәре, млн сум | | | | | |
| 2. | Уртача еллык исәбе, кеше | | | | | |
| 3. | Ресурсны сак куллану һәм әйләнә-тирәлекне саклау программасы | гамәлдә булу чоры | | | | |
| 4. | Мөмкин булган чик концентратларны, мөмкин булган чик ташландыкларны, мөмкин булган чик агынтыларны, калдыклар барлыкка килү лимитларын арттыруның билгеләнгән очраклары, саны | | | | | |
| 5. | Су куллану күләмнәре, мең куб метр, шул исәптән: | | | | | |
| 5.1. | җир өслеге чыганагыннан | | | | | |
| 5.2. | җир асты чыганагыннан | | | | | |
| 6. | Су агызу, мең куб метр, | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | шул исәптән: | | | | | |
| 6.1. | җир өсте су объектларына | | | | | |
| 6.2. | чистартмыйча | | | | | |
| 6.3. | җитәрлек чистартылмаган агынты сулар | | | | | |
| 6.4. | норматив чиста сулар (чистартмыйча) | | | | | |
| 7. | Әйләнешле һәм кабат кулланылышлы су белән тәэмин итү, мең куб метр | | | | | |
| 8. | Ташланган пычраткыч матдәләр массасы, дәүләт статистика хисаплылыгы мәгълүматлары буенча, № 2-тп формасы буенча (су хуҗалыгы), мең тонна | | | | | |
| 9. | Атмосферага пычраткыч матдә ташлау динамикасы, мең тонна: | | | | | |
| 9.1. | барлыкка килгән | | | | | |
| 9.2. | тотып алынган һәм йогышсызландырылган | | | | | |
| 10. | Калдыклар барлыкка килү динамикасы, мең тонна: | | | | | |
| 10.1. | барлыкка килгән | | | | | |
| 10.2. | үз җитештерүендә эшкәртелгән | | | | | |
| 10.3. | эшкәртүгә тапшырылган | | | | | |
| 10.4. | күмү өчен чыгарылган | | | | | |
| 11. | Җайланма һәм технология кертү, саны, шул исәптән: | | | | | |
| 11.1. | икенчел ресурсларны җыю һәм эшкәртү буенча | | | | | |
| 11.2. | сәнәгать калдыклары барлыкка килү күләмнәрен киметүгә ярдәм итүче технологияләр | | | | | |
| 11.3. | газ чистарту җайланмалары | | | | | |
| 11.4. | газ ягулыгына күчерелгән автотранспорт | | | | | |
| 11.5. | сәнәгый агынтыларны чистарту технологияләре | | | | | |
| 11.6. | башкасы | | | | | |
| 12. | әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынтыны киметергә булыша торган һәм ресурсларны сак куллану буенча технологияләр һәм җайланмалар кертүдән файда: | | | | | |
| 12.1. | ташландыкларны киметү, тонна | | | | | |
| 12.2. | агынтыларны киметү, тонна | | | | | |
| 12.3. | калдыклар барлыкка килүне киметү, тонна | | | | | |
| 13. | Әйләнә-тирәлекне саклау һәм экологик иминлек буенча программаларны һәм | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | чараларны финанслау, мең сум, шул исәптән түбәндәгеләр буенча: | | | | | |
| 13.1. | су ресурсларын саклау һәм рациональ куллану буенча | | | | | |
| 13.2. | атмосфера һавасын саклау буенча | | | | | |
| 13.3. | калдыкларны утильләштерү һәм эшкәртү буенча | | | | | |
| 13.4. | башкасы | | | | | |
| 14. | Предприятие территориясен яшелләндерү, гомуми мәйданыннан % | | | | | |
| 15. | Техноген һәлакәтләр, саны | | | | | |
| 16. | Табигатьтән файдалану буенча икътисад механизмын саклау һәм экологик түләүләрне вакытында кертү, мең сум | | | | | |

_________________________________________ /_____________________________/

М.У. (имза) (җитәкченең ФИА)

_________________

(дата)

"ЭКОлидер" республика
конкурсы уздыру турында
нигезләмәгә 2 нче кушымта

**“Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары”**
конкурс төркемендә "ЭКОлидер" республика конкурсында
катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация:
______________________________________________________________
2. ҖҮО органының тулы атамасы:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
3. Адресы: ТР муниципаль районы: ____________________ торак пункт:
_____________ урам: ____________________ йорт: ______________________________
4. ҖҮО органы җитәкчесенең ФИА:
______________________________________________________________
5. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның ФИА:
______________________________________________________________
Вазыйфасы:
______________________________________________________________
Эш телефоны, коды белән:
______________________________________________________________
Кесә телефоны:
______________________________________________________________
E-mail:_______________________________________________________
6. Эшчәнлек күрсәткечләре:

| Күрсәткечнең аталышы | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 |
|---|---|---|---|---|---|
| Шәһәр округлары һәм муниципаль районнар территориясендә табигать саклау чаралары буенча программалар булу | гамәлдә булу чоры | | | | |
| Әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынты өчен җирле бюджетка кертелгән түләүнең табигатьне саклау чараларын тормышка ашыруга тотылган суммага бәрабәре,% | | | | | |

______________________________________________________________/
М.У. (имза) (җитәкченең ФИА)

______________

(дата)

"ЭКОлидер" республика
конкурсы уздыру турында
нигезләмәгә 3 нче кушымта

**"Белем бирү оешмалары"**
конкурс төркемендә "ЭКОлидер" республика конкурсында
катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация:

______________________________________________________________

2. Белем бирү оешмасының тулы атамасы:

______________________________________________________________

3. Адресы: ТР муниципаль районы: _______________________ торак пункт:
______________ урам: ___________________ йорт: _____________________________

4. Белем бирү оешмасы җитәкчесенең ФИА:

______________________________________________________________

5. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның ФИА:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Вазыйфасы:

______________________________________________________________

Эш телефоны, коды белән:

______________________________________________________________

Кесә
телефоны:_____________________________________________________
E-mail:_______________________________________________________

6. Агымдагы елда экологик белем бирү һәм мәгърифәт эшчәнлегенә кыскача тасвирлама:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

7. Табигать саклау чараларын тормышка ашыру территориясе:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

8. Табигать саклау чараларында катнашучыларның гомуми саны:

______________________________________________________________

______________________________________ /____________________________________/
М.У. (имза) (җитәкченең ФИА)

______________
(дата)

"ЭКОлидер" республика
конкурсы уздыру турында
нигезләмәгә 4 нче кушымта

**"Иҗтимагый берләшмәләр һәм гражданнар"**
конкурс төркемендә "ЭКОлидер" республика конкурсында
катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация: ____________________________________________________________________

2. Оешманың тулы атамасы/гражданинның ФИА (тулысынча): ____________________________________________________________________

3. Адресы: ТР муниципаль районы: ____________________ торак пункт: __________
урам: ____________йорт: __________корпус:_________фатир:__________

4. Оешма җитәкчесенең ФИА: ____________________________________________________________________

5. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның ФИА: ____________________________________________________________________

Вазыйфасы: ____________________________________________________________________

Эш телефоны, коды белән: ____________________________________________________________________

Кесә телефоны:______________________________________________________
E-mail:__________________________________________________________

6. Иҗтимагый-әһәмиятле табигать саклау эшчәнлегенә кыскача тасвирлама:
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

7. Табигать саклау чараларын тормышка ашыру территориясе:
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

8. Табигать саклау чараларында катнашучыларның гомуми саны:
________________________________________________________________________________

/________________________________________/
М.У. (булганда) (имза) (җитәкченең/гражданинның ФИА)

________________

(дата)

"ЭКОлидер" республика конкурсы уздыру турында нигезләмәгә 5 нче кушымта

**"Массакүләм мәгълүмат чаралары"**
конкурс төркемендә "ЭКОлидер" республика конкурсында катнашучының мәгълүмат картасы

1.Номинация:
________________________________________________________________________________

2. Оешманың тулы атамасы/гражданинның ФИА (тулысынча):
________________________________________________________________________________

3. Адресы: ТР муниципаль районы: ____________________ торак пункт: ____________________ урам: ____________________ йорт: __________ **корпус:**_______________**фатир:**_____________________________________

4. Җитәкче ФИА:
________________________________________________________________________________

5. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның ФИА:
________________________________________________________________________________

Вазыйфасы:
________________________________________________________________________________

Эш телефоны, коды белән:
____________________________________________________________________________

Кесә телефоны:________________________________________________________________

E-mail:____________________________________________________________________

6. Иҗтимагый әһәмиятле табигать саклау эшчәнлегенә кыскача тасвирлама (ММЧдагы материаллар исемлеге):

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

7. Таралыш/массакүләм мәгълүмат чараларын күрсәтү территориясе:

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

_______________________________ /____________________________________/

М.У. (булганда) (имза) (җитәкченең/гражданинның ФИА)

________________

(дата)